**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «30» июленнән № 168

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә юлламасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2025 елның 04 июнендәге 137 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә юлламасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2025 елның 04 июнендәге 137 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5.9 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре» мобиль кушымтасы ярдәмендә электрон рәвештә видеоконференцэлемтә форматында.»;

1.2. 2.13.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.13.2. Гаризаны «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы ярдәмендә электрон рәвештә видеоконференцэлемтә форматында һәм/яки Бердәм, Республика порталы аша җибәргәндә мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Бердәм, Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гариза җибәрелгәнлеген раслый торган хәбәрнамә ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм бирелү датасы күрсәтелә.»;

1.3. 3.3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3. «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәте 2.0» мобиль кушымтасы ярдәмендә электрон формада видеоконференцэлемтә форматында муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү.

3.3.3.1. Гаризаны «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте 2.0» мобиль кушымтасы ярдәмендә бирү өчен мөрәҗәгать итүче:

Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы (ЕСИА) ярдәмендә махсуслаштырылган программа белән тәэмин ителештә авторизация уза;

программа белән тәэмин итү интерфейсы аша гаризалар кабул итүне алып баручы күпфункцияле үзәк хезмәткәренә видеошалтырату тәкъдим итә;

3.3.3.2. Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итүче хезмәткәре:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен идентификацияли;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан хәбәр ителгән мәгълүматларга һәм сайланган хезмәт күрсәтүгә нигезләнеп, гаризаның электрон формасын тутыра, шулай ук Регламентның 2.5.1 пунктында күрсәтелгән документларны соратып ала. .

гаризаны мөрәҗәгать итүчегә тикшерүгә һәм имзалауга (раслауга) файл рәвешендә тапшыра;

раслаганнан соң башкарма комитетка гариза һәм документлар пакеты җибәрә;

шәхесне идентификацияләү мөрәҗәгать итүченең йөзен паспорттагы фотосурәт белән чагыштыру юлы белән, шулай ук контроль сорауга дөрес җавап бирү юлы белән башкарыла. Шәхесне идентификацияләү сораштыру вакытында дөрес җавап булган очракта уңышлы дип санала.

Гаризаның электрон формасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында билгеләнгән структурага туры килә.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан сайланган системага мәгълүмат бирү ысулы буенча мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү турында хәбәр ителә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

3.3.3.3. 3.3.3 пунктында билгеләнгән административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: Башкарма комитетка җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Е.А. Тарнавский